ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.11.2022 Олы Кайбыч ав. № 521

Муниципаль дәрәҗәдә хисап чорында декомпозацияләнгән «Гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматларны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын раслау турында

«2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясен үстерүнең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы РФ Президенты Указлары нигезендә Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Муниципаль дәрәҗәдә хисап чорында декомпозацияләнгән «Гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматларны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын кушымтада карлаганча расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы
Башкарма комитетының
«_____» ___________________
номерлы карарына кушымта

**Муниципаль дәрәҗәдә хисап чорында декомпозацияләнгән «Гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматларны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламенты**

## I. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге муниципаль дәрәҗәдә хисап чорында декомпозацияләнгән «Гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматларны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламенты (алга таба – Регламент) Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге турында» 2021 елның 04 февралендәге 68 номерлы Указы, «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен исәпләү методикасын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы турында» 2009 елның 31 декабрендәге 920 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы «Контроль» модуленең эшләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 18 апрелендәге 361 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эшләнгән һәм муниципаль дәрәҗәгә декомпозияләнгән «Гармонияле үсеш һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар» күрсәткече (алга таба - Күрсәткеч) зурлыкларын җыю тәртибен билгели.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында күрсәткеч зурлыкларын җыю һәм мониторинглау өчен җаваплылык үзәге булып Татарстан Республикасы муниципаль районы Башкарма комитетының тиешле вәкаләтләргә ия булган мәдәният бүлеге тора (алга таба – җаваплылык үзәге).

Күрсәткечнең кыйммәтләре турында мәгълүмат җиткерүчеләр (алга таба - Мәгълүмат җиткерүчеләр) булып дәүләт, муниципаль һәм башка оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка инициаторлар тора.

## II. Төп төшенчәләр һәм аңлатмалар

**Тәрбия** – шәхес үсешенә, укучыларның үз-үзен билгеләве һәм социальләшүе өчен социомәдәни, рухи-әхлакый кыйммәтләр һәм Россия җәмгыятендә кабул ителгән кеше, гаилә, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләрендә үз-үзләрен тоту кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә шартлар тудыруга, укучыларда патриотизм, гражданлык, Ватанны саклаучылар истәлегенә һәм Ватан Геройлары батырлыкларына хөрмәт хисләрен булдыруга, закон һәм хокук тәртибе, хезмәт кешесе һәм өлкән буын, Россия Федерациясе күпмилләтле халкы мәдәни мирасына һәм традицияләренә үзара хөрмәт, табигать һәм мохиткә сакчыл мөнәсәбәт булдыруга юнәлдерелгән эшчәнлек.

**Гражданлык тиңдәшлеге** - гражданнарның аңында аларның үз дәүләтләренә, халкына, җәмгыятькә, гореф-гадәтләренә, ил язмышы өчен җаваплылыгына, гражданлык хокукларын һәм бурычларын үтәү зарурлыгына каравын формалаштыру, шулай ук рухи-әхлакый кыйммәтләр, социаль теләктәшлек, сәнгать, тел һәм дөнья күрү үзенчәлекләрен чагылдыра торган Россия җәмгыятенең база кыйммәтләренә бирелгәнлеге.

«**Укучылар өчен мәдәният**» **ведомствоара проекты** - Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының мәдәни-мәгариф проекты.

## III. Күрсәткечне исәпләү стандарты

«Гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар» күрсәткечен исәпләп чыгару өчен, түбәндәге декомпозицияле ярдәмче күрсәткечләр кулланыла:

1. Грантлар һәм стипендияләр алу өчен юнәлдерелгән заявкалар саны, яшь авторлар һәм башкаручылар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән, берәмлек;
2. Проектларны гамәлгә ашыру өчен, шул исәптән коммерциягә карамаган оешмаларга грант ярдәме кысаларында, Россия Федерациясе халыкларының рухи-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләре нигезендә Россия граждан тәңгәллеген ныгытуга Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән юнәлтелгән гаризалар саны, берәмлек;
3. Квалификация күтәрүне узган мәдәният өлкәсе хезмәткәрләре саны, кеше;
4. «Мәктәп укучылары өчен мәдәният» ведомствоара проектында катнашучылар саны, берәмлек;
5. Мәктәп укучылары өчен мәдәни-агарту программаларында катнашучылар саны, шул исәптән «Җиңү юллары» Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән, берәмлек;
6. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән Россия халыкларының рухи-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләре нигезендә Россия граждан тәңгәллеген ныгытуга юнәлдерелгән коммерциягә карамаган оешмалар чараларына килүчеләр саны, берәмлек;

7. «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гомумроссия граждан бердәмлеген ныгытуга юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны» берәмлек.

## IV. Мәгълүмат җыю тәртибе, сроклары һәм формалары

Күрсәткечне исәпләү өчен кирәкле ярдәмче күрсәткечләрнең әһәмияте турында мәгълүмат бирү рәвешләре Регламентның 1-7 нче кушымталарына туры килергә тиеш. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының (алга таба - Министрлык) - «Таткультресурсцентр» ДБУнең Җаваплылык үзәге хезмәткәре тарафыннан тутырыла һәм проектлау офисына җибәрелә торган Күрсәткеч кыйммәтләре турында җыелма форма Регламентка 8 нче кушымтада тәкъдим ителә.

Мәгълүмат җиткерүчеләр тарафыннан Мәгълүмат үзәгенә электрон рәвештә яки кәгазь чыганакта, оешма җитәкчесе кул куйган һәм мөһер беркетелгән мәгълүмат тапшырыла.

Мәгълүмат кәгазьдә һәм электрон рәвештә кергән формалардан мәгълүмат мәгълүмат Үзәк җаваплылык үзәгендә махсус форматта мәгъләматлар базсына кертелә (Microsoft Excel, Microsoft Access h.б.). Шул ук вакытта кәгазьдә кергән мәгълүмат әлеге вәкаләтләр беркетелгән җаваплылык үзәге хезмәткәре тарафыннан таблицага кулдан күчерелә. Агрегацияләнгән мәгълүмат Кайбыч муниципаль районы территориясендә урнашкан мәгълүмат җиткерүчеләр мәгълүматына нигезләнеп төзелә, Җаваплылык үзәге тарафыннан Министрлыкның «Таткультресурсцентр» ДБУнең проект офисына электрон документ әйләнеше системасын кулланып, хисап чорыннан соң килүче айның 5 числосына кадәр тапшырыла һәм муниципаль электрон исәпкә алу журналында 5 ел дәвамында саклана. Алга таба «Таткультресурсцентр» ДБУ Татарстан Республикасының барлык муниципаль районнары буенча үз мәгълүматларын электрон документлар әйләнеше системасын кулланып, хисап чорыннан соң килүче айның 10 числосына кадәр Министрлыкка тапшыра. Министрлык адресына тапшырыла торган мәгълүматның (мәгълүматларның) эчтәлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикасын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карары нигезендә билгеләнә.

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы буенча «Яшь авторлар һәм башкаручылар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән грантлар һәм стипендияләр алу өчен юнәлдерелгән заявкалар саны» ярдәмче күрсәткече хисап мәгълүматлары

| т/б № | Заявкалар җибәрү инициаторы | Дата | Грантлар һәм стипендияләр алу өчен җибәрелгән заявкалар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |

2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы буенча «Проектларны гамәлгә ашыру өчен җибәрелгән заявкалар саны, шул исәптән Россия Федерациясе халыкларының рухи-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләре нигезендә Россия граждан тәңгәллеген ныгытуга юнәлдерелгән коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән грант ярдәме кысаларында» ярдәмче күрсәткече хисап мәгълүматлары

| т/б № | Заявкалар җибәрү инициаторы | Дата | Проектларны гамәлгә ашыру өчен җибәрелгән заявкалар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |

3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы буенча «Квалификациясен күтәрү узган мәдәният өлкәсе хезмәткәрләре саны» ярдәмче күрсәткече хисап мәгълүматлары

| т/б № | Мәгълүмат җиткерүче | Дата | Квалификациясен күтәрү узган мәдәният өлкәсе хезмәткәрләре саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |

4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы буенча «Укучылар өчен мәдәният» ведомствоара проектында катнашучылар саны» ярдәмче күрсәткече хисап мәгълүматлары

| т/б № | Мәгълүмат җиткерүче | Дата | Проектта катнашучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |

5 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы буенча «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән Россия халыкларының рухи-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләре нигезендә Россия граждан тәңгәллеген ныгытуга юнәлдерелгән коммерциячел булмаган оешмалар чараларына килүчеләр саны» ярдәмче күрсәткече хисап мәгълүматлары

| т/б № | Мәгълүмат җиткерүче | Чара исеме | Дата | Катнашучылар саны |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |

6 нчы кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы буенча «Укучылар өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән мәдәни-агарту, шул исәптән «Җиңү юллары» программаларында катнашучылар саны» ярдәмче күрсәткече хисап мәгълүматлары

| т/б № | Мәгълүмат җиткерүче | Программа исеме | Дата | Катнашучылар саны |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |

7 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы буенча «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гомумроссия граждан бердәмлеген ныгытуга юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны» ярдәмче күрсәткече хисап мәгълүматлары

| т/б № | Мәгълүмат җиткерүче | Чара исеме | Дата | Катнашучылар саны |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |

8 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы буенча «Гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар» күрсәткече буенча мәгълүматлар мониторингы формасы

| т/б № | Ярдәмче күрсәткеч исеме | Ярдәмче күрсәткеч план буенча * | Ярдәмче күрсәткеч фактта | Планнан тайпылыш сәбәпләре ** |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Яшь авторлар һәм башкаручылар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән грантлар һәм стипендияләр алу өчен юнәлдерелгән заявкалар саны, берәмлек | | | |
| 2 | Проектларны гамәлгә ашыру өчен җибәрелгән заявкалар саны, шул исәптән Россия Федерациясе халыкларының рухи-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләре нигезендә Россия граждан тәңгәллеген ныгытуга юнәлдерелгән коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән грант ярдәме кысаларында, берәмлек | | | |
| 3 | Квалификациясен күтәрү узган мәдәният өлкәсе хезмәткәрләре саны | | | |
| 4 | «Укучылар өчен мәдәният» ведомствоара проектында катнашучылар саны, берәмлек | | | |
| 5 | Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән Россия халыкларының рухи-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләре нигезендә Россия граждан тәңгәллеген ныгытуга юнәлдерелгән коммерциячел булмаган оешмалар чараларына килүчеләр саны, берәмлек | | | |
| 6 | Укучылар өчен Татарстан Республикасы бюджеты | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | акчалары исәбеннән мәдәни-агарту, шул исәптән «Җиңү юллары»программаларында катнашучылар саны, берәмлек | | | |
| 7 | Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гомумроссия граждан бердәмлеген ныгытуга юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны, берәмлек | | | |

* - 3 нче графа Татарстан Республикасы муниципаль районнары өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан формалаштырыла

** - план күрсәткечләре үтәлмәгәндә 5 нче графа Җаваплылык үзәге тарафыннан тутырыла